ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.12.2025 ел Баулы шәһәре №171

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 июнендәге 135 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Граждан оборонасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 23 июлендәге 240-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 5 февралендәге 58 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 10 июнендәге 544 номерлы карары нигезендә, Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 июнендәге 135 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атаманы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Баулы муниципаль районы территориясендә муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү яисә килеп чыгу куркынычы янаганда эвакуация чараларын үткәрүне тәэмин итү эшен оештыру турындагы Нигезләмәне раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Баулы муниципаль районы территориясендә муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү яисә килеп чыгу куркынычы янаганда

эвакуация чараларын үткәрүне тәэмин итү эшен оештыру турында беркетелгән Нигезләмәне расларга.»;

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм уздыру эшен оештыру турындагы Нигезләмәдә:

атаманы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Баулы муниципаль районы территориясендә муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү яисә килеп чыгу куркынычы янаганда эвакуация чараларын үткәрүне тәэмин итү эшен оештыру турында нигезләмә»;

1.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Нигезләмә Баулы муниципаль районы территориясендә муниципальара яисә региональ характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу яисә килеп чыгу куркынычы булганда эвакуация чараларын үткәрүне тәэмин итү эшен оештыру тәртибен билгели.»;

1.2. пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эвакуация населения - комплекс мероприятий по организованному перемещению населения из зон опасностей и его размещению в безопасных районах;»;

2.1. пунктында. «табигый һәм техноген характердагы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2. пунктында. «табигый һәм техноген характердагы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Эвакуация чараларын үткәрү гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы булган территорияләрдә яисә гадәттән тыш хәлләр зоналарында булган кешеләрнең гомерен һәм сәламәтлеген саклап калу максатларында гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карар 2026 елның 20 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров